# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге составына керүче Адав-Толымбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

13.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - урамнарны яктыртуны җайлау; -Адав-Толымбай авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәй көне территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт күрсәтү өчен килешү буенча түләү; мәдәният йорты янында койма урнаштыру). өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыененың нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 612 катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 310 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 305 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге составына керүче Адав-Толымбай авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - урамнарны яктыртуны җайлау; - Адав-Толымбай авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәй көне территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт күрсәтү өчен килешү буенча түләү; мәдәният йорты янында койма урнаштыру). өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Адав-Толымбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ________ А.Ф. Әхмәтҗанов

Адав-Толымбай авыл җирлеге
башлыгы _______________ А.Ф. Әхмәтҗанов